ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30 июня 2016 г.**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 1698**

Шәһәр тибындагы Васильево бистәсенең, Солнечная урамы, 46 нчы йорт адресындагы җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез милек корылмаларын алу турында

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 26.09.2013 ел, №2178 карары белән расланган 2013-2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатыннан чыгып, 21.07.2007 ел, №185-ФЗ «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд турында» Федераль закон, Торак, Җир кодекслары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Авария хәлендә табылган һәм сүтелергә тиешле  Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Солнечная урамы, 46 нчы күпфатирлы торак йорт адресындагы җир кишәрлеген, шулай ук, кушымта булып бирелә торган исемлек нигезендә күрсәтелгән йортта урнашкан күчемсез милек объектларын муниципаль ихтыяҗлар өчен алырга.
(кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайты составында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:
- алына торган күчемсез милек хокукына ия булучыларга;
- күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;
- МКУ «Торак сәясәте департаменты» на җибәрергә.

4. МУ «Зеленодольск муниципаль районының Мөлкәт һәм Җир мөнәсәбәтләре палатасы» әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сахибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
30 июнь 2016 ел №1706

Авария хәлендә табылган һәм сүтелергә тиешле, шәһәр тибындагы Васильево бистәсенең, Солнечная урамы, 46 нчы номерлы күпфатирлы торак йортның алынырга тиешле күчемсез милек корылмалары
(торак һәм торак булмаган бүлмәләр)
ИСЕМЛЕГЕ

| Квартира № | Кадастр яки объектның шартлы номеры |
|---|---|
| 4 | 16:20:0170101:5743 |